Чыганак: Фән һәм мәктәп=Наука и школа. – 2011. – №. 11. – Б. 18-19.

# СИБГАТ ХӘКИМ — ТУГАН ЯК ҖЫРЧЫСЫ

(11 нче сыйныф)

*А.Шиһапова, 4 нче урта мәктәп укытучысы, Яр Чаллы шәһәре*

**Тема.** С. Хәким — туган як җырчысы.

**Максат.** С.Хәкимнең туган як темасын яктыртკан шигырьләрен уку, анализлау. Аларның идея эчтәлеген ачу. Шагыйрьнең туган якка, аның табигатенә, кешеләренә булган мөнәсәбәтен ачыклау. Шагыйрьнең әдәбият та һәм музыка сәнгатендә тоткан урынын билгеләү. Туган якка мәхәббәт хисләре тәрбияләү, эстетик зәвык булдыру.

**Җиһазлау.** С.Хәким портреты; аның иҗатын чагылдырган плакатлар; шагыйрьнең китапларыннан күргәзмә; магнитофон; С.Хәким шигырьләренә иҗат ителгән җырлар (аудиоязмалар).

**Дәрес барышы**

*I. Оештыру.*

*II. Актуальләштерү. Кереш сүз.*

Укытучы. С.Хәким тормышы һәм иҗаты буенча алдагы дәресләрдә алган белемнәрне искә төшерәбез.

- С.Хәким кайчан һәм кайда туган?

- Аның иҗатында нинди темалар өстенлек итә?

- Шагыйрь иҗатына нинди үзенчәлекләр хас?

- С.Хәким иҗаты ничек бәяләнгән?

С.Хәким иҗатында төп темаларның берсе — туган як темасы, дидек. Бүген шагыйрьнең туган ягына багышланган әсәрләрен өйрәнербез.

Туган җир,туган туфрак... Аңа булган тойгыларны һәр шагыйрь үзенчә әйтә, җырлый. С.Хәким дә — Казан артын поэтик образга әйләндергән әдип. Без аны, бер дә шикләнмичә, туган ягын яраткан шагыйрь, дип әйтә алабыз. Ул — халыкчан шагыйрь, ә халыкчанлык - халык күңеленә, аңына мәңгегә керә алу, шигырьләрендәге хисләрне башкаларга да җиткерү ул. С.Хәким, барыннан да элек — лирик шагыйрь. Аның шигырьләрендә табигый моң ага, укучы аларны йөрәгенә якын алган сизми дә кала.

Композитор Р.Яхин С.Хәким шигырьләре турында болай ди: «Аның шигырьләре лиризм белән шулкадәр сугарылганнар, алар үзләреннән-үзләре көйгә салыну сорап торалар. «Таң атканда», «Чын йөрәктән»,»Фазыл чишмәсе», «Юксыну», «Сусау», «Башка берни дә кирәкми» җырлары — моның ачык мисалы. Алар инде халык җырлары булып киттеләр».

«Таң атканда» шигырен уку.

Туган як темасы шагыйрьнең бөтен иҗатын иңләп үтә. Аның туган җир матурлыгын сурәтләп язган әсәрләре, шигъриятнең иң югары ноктасын билгеләп кенә калмыйча, татар поэзиясенең иң уңышлы әсәрләре арасында урын алды. Хәзер без шул әсәрләр белән танышырбыз.

**«Гел кояшка карый тәрәзәләрең» шигыре**

Укытучы шигырьне сәнгатьле укый.

Шигырьне укучылар үзлектән укый.

Әсәрне анализлау.

- Шигырьдә сүз ни турында бара? (Шагыйрьнең туган ягы турында. Шагыйрьнең туган ягы — Казан арты. Ул биргә еш кайта иде.)

- Шагыйрь Казан арты турында нилэр сөйли? (Казан арты аңа бик тә якын, чөнки монда аның теле ачылган. Монда ул, бөек Тукай моңын ишетеп, туган җирнең йомшак җилләрендә иркәләнеп үскән.)

- Шигырьдә «татлы хыял» эпитеты нәрсәгә хезмәт итә? (Шагыйрьнең «хыяллары татлы», чөнки ул туган ягының, аның кешеләренең киләчәгенә ышаныч, өмет белән карый.)

- Шигырьдә символик мәгънәгә ия сүзләр бармы? (Кояш — бәхет, өмет, шатлык символы. Ул — алдагы якты көн символы.)

**«Башка берни дә кирәкми» шигыре**

Магнитофоннан җырны тыңлау (Татарстанның халык артисткасы Венера Шәрипова башкаруында).

Шигырьне укучылар мөстәкыйль укый.

Шигырьне анализлау.

- Шигырьне өлешләргә бүлик. Беренче өлештә сүз ни турында бара? (Туган як бик кадерле, аны бернигә дә алыштырып булмый.)

- Икенче өлештә нәрсә турында сөйләнә? («Иң кадерле се — үзең чапкан печән исен иснәү», — ди автор.)

- Өченче өлешне табабыз. Үзем тапкан чишмәләрнең суын эчүдән дә рәхәтрәк нәрсә юк.

- Дүртенче өлешне табабыз. Тормышта якын дусларың булу кирәк.

- Һәр өлештә дә шагыйрьнең теләкләрен нәрсә берләштерә? (Болар барысы — лирик геройның яшәү мәгънәсе.)

- Шигырьнең төзелешенә игътибар итик. Шигырьнең исеме һәр куплетта кабатланып килә. Кабатлаулар нигә кирәк? (Шигырьдәге фикерне көчәйтү өчен.)

- Әйе, туган җирдән дә кадерле нәрсә юк. Шуңа күрә илһамының чишмә башын эзләп, шагыйрьнең туган авылына киләләр, туган нигезенә баш иялэр. Үз баласын олылап, хөрмәтләп килгәннәрне дөньяга шагыйрь бүләк иткән авыллар каршылый, музейлар ачыла, хатирәләр сөйли. Күлле Киме авылы мәктәбендә урнашкан С.Хәким музее да шундый игелекле эш башкара. Музей 1981 елда Сибгат аганың 70 еллык юбилее көннәрендә оеша. Аны ачу тантанасына шагыйрь дуслары белән кайта, үз куллары белән тасманы кисеп, эчкә үтә. Шул көнне музейның истәлекләр дәфтәренә мондый юллар язып калдыра: «Туган җиргә, туган туфракка кайттым, яшьлеккә, балачакка, истәлекләргә. Миңа багышланган бу музей шуларның барысын да искә төшерде...».

Шагыйрә Г.Зәйнашева болай дип сөйли: «Халык көйләрен, бүгенге заманның уңышлы җырларын С.Хәким тирән мәхәббәт белән ярата, аларның күбрәк булуын кайгырта иде. Үзенең чыгышларында, мәкаләләрендә халкыбызның борынгы көйләрен, борынгы моңнарын сакларга, тукми-чәчми киләчәк көннәргә, киләчәк буыннарга алып барырга кирәклеген өзми-куймый кабатлый иде...».

С.Хәкимнең туган як турында язылган әсәрләрен өйрәнүне дәвам итәбез.

**«Бу кырлар, бу үзәннәрдә» шигыре**

Шигырьне сәнгатьле уку.

Укучылар үзлектән укый.

Шигырьне анализлау.

- Бу шигырьдә шагыйрьнең туган якка мөнәсәбәте ничек чагыла? (Лирик геройның туган ягын сагынуы, аңа ашкынуы күрсәтелә. Монда аның балалык эзләре калган, яшьлек мәхәббәте кабынган.)

- Шигырьдә кабатлауларны табыгыз. (Кайтам, кайтам туган якларыма!)

- Шагыйрь нигә кабатлый? (Кабатлау сагыну хисенең никадәр көчле икәнен белдерә.)

- Соңгы куплетның соңгы юлларына игътибар итик.

Кайтам, кайтам туган якларыма.
Ашкындырып көткән юллар бар.

- Бу юллар ни турында сөйли? (Шагыйрьне туган ягында һәрчак көтәләр. Ул шуны белә, шуның белән үзен юата.)

- С.Хәким белән С.Садыйкова якын дуслар булганнар. Алар әдәби багланышта торганнар. Сара апа Садыйкова С.Хәкимнең бик күп шигырьләренә көйләр язган. Шундый шигырьләрнең берсе — "Сусау".

**«Сусау» шигыре**

«Сусау» шигырен уку (язмада җыр тыңларга мөмкин).

Укучылар мөстәкыйль укый.

Шигырьне анализлау.

- Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез. Лирик геройның хисләрен, кичерешләрен күрсәткән юлларны табыгыз.

- Шигырьдә кайсы сүз кабатлана? (Сусау.)

- Сусау" төшенчәсенә нинди мәгънә салынган? Нигә аны автор кабатлый? (Әлеге сагынуның дәрәҗәсен билгели.)

- Лирик герой бәхетне нәрсәдә күрә? (Туган ягы, аның кешеләре белән үзен бәхетле хис итә. Алар белән аралашып яшәргә омтыла.)

- Укучылар, сезгә С.Хәкимнең туган як турында булган бер шигырен ятларга кушылган иде.

Укучыларның шигырьләре тыңлана, билгеләр куела.

- Без укыган, тыңлаган шигырьләрдә охшашлык бармы? Аларны нәрсә берләштерә?

Шигырьләрдә туган якны сагыну хисләре чагыла. Автор туган якның гүзәллегенә соклана, аның халкына дан җырлый. Шагыйрь үз бәхетен халык язмышы белән бәйләп карый. Халык бәхетле булса, ул да бәхетле.

- С.Хәкимнең шигырьләре туган ягына, туган авылына чиксез мәхәббәт белән сугарылган, чөнки ул туган ягын бик яраткан. Җае чыккан саен, биргә кайткан. Кайткан саен, җанына илһам алып, кочак-кочак шигырьләр язган. Бу исә шагыйрь язмышының туган туфрактан, туган яктан аерылгысыз булуын күрсәтә.

С.Хәким сүзләренә язылган «Әй, язмыш, язмыш» җырын тыңлау.

*III. Йомгаклау. Өй эше.* С.Хәким шигырьләрен сәнгатьле укырга. С.Хәким шигырьләренә көй язган композиторларның исемнәрен белеп килергә. Алар иҗат иткән җыр исемнәрен язып килергә.